Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советының егерме тугызынчы утырышы

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

30 октябрь, 2023 ел № 75

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге уставының 86, 87, 88 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы 2015 елның 19 июнендәге 19 номерлы (Советның 2016 елның 5 февралендәге 27, 2017 елның 20 гыйнварындагы 60/1, 2017 елның 2 октябрендәге 81/22, 2018 елның 29 гыйнварындагы 92, 2018 елның 16 июлендәге 105, 2019 елның 28 мартындагы 124, 2019 елның 28 октябрендәге 139, 2020 елның 12 ноябрендәге 9, 2021 елның 22 октябрендәге 26 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Н.В. Морозов

Питрәч муниципаль районының
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге
Советы карарына кушымта
30 октябрь, 2023 ел, № 75

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Муниципаль сайлаулар» 12 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә:

**«12 статья. Муниципаль сайлаулар**

1. Җирлектә муниципаль сайлаулар, гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән, Җирлек Советы депутатларын сайлау максатларында уздырыла.

2. Җирлек Советы депутаты итеп тавыш бирү көненә 18 яшькә җиткән һәм сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданы сайланырга мөмкин.

3. Муниципаль сайлаулар Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә. Муниципаль сайлауларны билгеләү турындагы карар тавыш бирү көненә кадәр 90 көннән дә иртәрәк һәм 80 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш. Әлеге карар кабул ителгән көненнән соң 5 көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыгарга тиеш.

Вакытыннан алда сайлаулар билгеләгәндә әлеге статьяда күрсәтелгән сроклар кыскартылырга мөмкин, әмма кимендә өчтән беренә.

Федераль законнарда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән очракларда муниципаль сайлаулар Татарстан Республикасы Питрәч районы (алга таба - районның сайлау комиссиясе) территориаль сайлау комиссиясе яисә суд тарафыннан билгеләнә.

4. Муниципаль сайлауларны әзерләү һәм уздыру үз компетенцияләре чикләрендә район сайлау комиссиясенә йөкләнә.

5. Җирлек Советы депутатларын сайлаулар «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

6. Җирлек Советы депутатлары сайлау округына сайлаучылар вәкиллегенең уртача нормасы нигезендә төзелә торган бермандатлы сайлау округлары буенча сайлана. Сайлау округына сайлаучылар вәкиллегенең уртача нормасы Җирлек территориясендә яшәүче һәм җирлек территориясендә теркәлгән сайлаучыларның гомуми санын федераль законнар нигезендә төзелә торган сайлау округлары санына бүлү юлы белән билгеләнә.

7. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның иң күп тавышын җыйган теркәлгән кандидат бермандатлы сайлау округы буенча сайланган дип танылa. Теркәлгән кандидатлар тавышларны бертигез җыйса, алданрак теркәлгән кандидат сайланган дип санала.

Әгәр бермандатлы сайлау округында тавыш бирү Советы депутатларын сайлауларда бер кандидатура буенча үткәрелсә, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышларының кимендә 50 процентын җыйган кандидат сайланган дип санала.

8. Җирлек Советы депутатларын сайлауларның нәтиҗәләре рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә).».

2. «Депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу буенча тавыш бирү» 13 статьясында:

а) 5 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Җирлек Советы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

«8. Җирлек Советы инициатив төркеме үтенечнамәсен караганда, чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләгәндә Җирлек Советы депутаты тиешле депутат аны чакыртып алу өчен нигез буларак күрсәтелә торган хәлләр уңаеннан аңлатмалар бирергә, кирәкле документларны тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән депутат Җирлек Советы утырышын уздыру көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча алдан ук аларны уздыру вакыты һәм урыны турында язмача хәбәр ителергә тиеш.»;

в) 12 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

«12. Чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын рәсми ясаганнан соң 5 көн эчендә җирлек советы инициатив төркемгә һәм аның чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында җирлекнең тиешле депутатына язма хәбәр итә.».

3. «Җирле үзидарәнең сайланулы органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты статусы» 30 статьяның 4 өлешендә:

а) 12 пунктта:

«а» пунктчасында «, Җирлек сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында:

«, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис) сүзләренә алмаштырырга;

б) 4.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4.3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис) сүзләренә алмаштырырга;

г) 4.4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

д) түбәндәге эчтәлекле 4.5 пункт өстәргә:

«4.5. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый вазыйфаларны үтәмәгән очракта «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый вазыйфаларны үтәмәү күрсәтелгән затларга «коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 13 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 3 өлешләрендә каралган тәртиптә бәйле булмаган дип танылa.».

4. «Яңа сайланган Җирлек Советы эшен оештыру» 32 статьясындагы 1 өлешендә «, ә ул булмаган очракта - Җирлек сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга.

5. « Җирлек Советы композициясе» 33 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктын үз көчен югалткан дип санарга.

6. «Җирлек Башлыгы статусы» 43 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункт өстәргә:

«5.1. Җирлек Башлыгы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны үтәмәгән очракта коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.».

7. «Җирлек Башлыгы урынбасары» 46 статья-сына түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8. Җирлек башлыгы урынбасары «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны үтәмәгән очракта аңа бәйле булмаган хәлләр нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә ачыкланган очракта, чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.».

8. САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ VII бүлеген гамәлдән чыгарырга.

9. «Җирлек Советы депутаты, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләрен» 58 статьясындагы 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ревизия комиссиясе әгъзаларына орган эшендә катнашу вакытына Җирлек Советы карарлары нигезендә акчалата компенсация түләнә.».

10. «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү), ышанычны югалтуга бәйле рәвештә:

а) 1 өлештә:

- 1 пунктта «анын ягы булган» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

- 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау йә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру турында»;

б) 2 өлештә «яклау һәм (яисә) җайга салу чараларын» сүзләреннән соң «мәнфәгатьләр конфликты» сүзләрен өстәргә, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, аңа буйсынган зат анын ягы булып тора.».